**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 17 сентябрендәге 3938 номерлы карары**

**Вахитов районының Жуковский урамындагы**
**территорияне ызанлау проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, «Беренчел документацияне әзерләү үзәге» муниципаль унитар предприятиесе гаризасы нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43, 45, 46 статьяларына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 24 июнендәге 2478 номерлы карары белән расланган «Центр» территориясен планлаштыру проектына, 2023 елның 10 июлендәге 305-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең гамәлдән чыгуын тану хакында»гы федераль законның 8 статьясына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 19 июнендәге 2596 номерлы «Казан шәһәре Вахитов районының Жуковский урамы чикләрендәге территорияне ызанлау проектын әзерләү турында»гы карарына таянып:

1. **Карар бирәм**:

1.1. әлеге карарның кушымтасы нигезендә Вахитов районының Жуковский урамындагы территорияне ызанлау проектын расларга;

1.2. ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, билгеләнә торган кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (кушымта) (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге

карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга;

1.3. ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, билгеләнә торган кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (кушымта) (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге карарны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга;

1.4. әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

2. Гражданка Ф.Ф.Рәхмәтуллинага **тәкъдим итәм:**

2.1. җир кишәрлегенә дәүләт кадастр исәбе үткәрү һәм ясала торган җир кишәрлегенә карата муниципаль милек хокукын теркәү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә;

2.2. җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә куйганнан соң, Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә адреслы номер бирү һәм белешмәләрне Дәүләт адреслар реестрына кертү өчен җир кишәрлегенең кадастр номеры турында мәгълүматны тапшырырга;

2.3. җир кишәрлегеннән алга таба файдаланганда:

2.3.1. инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең куркынычсызлыгын һәм әлеге челтәрләрне эксплуатацияләүче оешмаларның аларга тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итәргә;

2.3.2. территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар өчен билгеләнгән чикләүләрне үтәргә;

2.3.3. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2018 елның 16 октябрендәге 31 номерлы әмере нигезендә Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Жуковский урамы, 4 йорт адресы буенча урнашкан «Земство идарәсе бинасы» төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты (XIX гасыр ахыры, архитекторы билгесез) территориясеннән файдалану режимнарын, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2017 елның 13 мартындагы 218од номерлы әмере белән расланган Казан шәһәренең төбәк

əһəмиятендəге тарихи җирлек территориясе чиклəрендə шəһəр төзелеше регламентларына талəплəрне һəм сак предметын, Татарстан Республикасы мəдəни мирас объектларын саклау комитетының 2023 елның 1 декабрендəге 953-п номерлы əмере, Татарстан Республикасы Мəдəният министрлыгының 2010 елның 1 апрелендəге 183 номерлы «Истəлекле урын территориясен файдалануның характеры, əлеге территориядəн файдалануга чиклəүлəр һəм хуҗалык эшчəнлегенə талəплəр, Казан шəһəренең истəлекле урыннары территориясендə проектлау һəм төзү турында нигезлəмəне раслау хакында»гы əмере белəн расланган «Казан шəһəренең XI-XVIII гасырлардагы тарихи үзəгенең мəдəни катламы» федераль əһəмияттəге мəдəни мирас объектына карата чиклəүлəрне үтəргə.

3. Əлеге карарның үтəлешен контрольдə тотуны Казан шəһəре Башкарма комитеты Җитəкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмəтҗановка **йөклим**.

**Җитəкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 17 сентябрендәге
3938 номерлы карарына
кушымта

**Вахитов районының Жуковский урамындагы территорияне ызанлау проекты**

Вахитов районының Жуковский урамындагы территорияне ызанлау проектына түбәндәгеләр керә:

I. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, билгеләнә торган кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән территорияне ызанлау проекты турындагы нигезләмә.

II. Территорияне ызанлау сызымы.

Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, билгеләнә торган кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып торалар һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

## I. Территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә

Ызанлау проекты Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 24 июнендәге 2478 номерлы карары белән расланган «Центр» территориясен планлаштыру проекты чикләрендә Вахитов районы Жуковский урамында урнашкан территориягә эшләнгән.

Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы нигезендә территорияләрне ызанлау проектының чикләре ФЗ-124 – гомумшәһәр үзәгенең күпфункцияле зонасында урнашкан. Расланган территорияне планлаштыру проекты нигезендә барлыкка килә торган җир кишәрлеге ОМИ зонасында – үзәк тарихи районның күпфункцияле (катнаш) төзелеш зонасында һәм өлешчә урамнар һәм юллар территориясе чикләрендә урнашкан.

Җир кишәрлеге тарихи җирлекнең ярдәмче зонасы чикләрендә урнашкан.

Территорияне ызанлау проекты муниципаль милектә булган 16:50:010611:674 кадастр номерлы җир кишәрлеген дәүләт милке чикләнмәгән җирләр белән яңача бүлү юлы белән :ЗУ1 җир кишәрлеген ясауны күз алдында тота.

Җир кишәрлеген яңадан бүлү беренчел җир кишәрлеге белән билгеләнә торган кызыл линияләрнең бер-берсенә кереп урнашуын булдырмау максатыннан башкарыла.

Җир кишәрлегенең арта торган өлешен тәшкил итә торган территория аз үлчәмле, төзелеш өчен мөстәкыйль әһәмияткә ия түгел.

Шулай ук территорияне ызанлау проектында кызыл линияләрне үзгәртү күздә тотыла. Кызыл линияләрне үзгәртү, гамәлдәге юлны фактта узуны исәпкә алып, фактта җирдән файдалану чикләрендә башкарыла.

Таблица

| **Кишәрлек номеры** | **Мәйданы, кв.м** | **Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** |
|---|---|---|---|
| :ЗУ1 | 361 | 16:50:010611:674 | Эшлекле идарә;<br>Җәмәгать туклануы |

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгәнчә, җир кишәрлекләре ясала торган җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше һәм рөхсәт ителгән файдалану төре ясала торган җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше һәм рөхсәт ителгән файдалану төре дип танылa. Шулай итеп, ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре турындагы белешмәләр беренчел җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төре турындагы белешмәләргә туры килә.

Ясала торган җир кишәрлеге Ц – территориаль зонасында – шәһәр үзәгенең катнаш төзелеш зонасында урнашкан.

Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә Ц территориаль зонасында барлыкка килә торган җир кишәрлегенең иң чик минималь һәм максималь күләме билгеләнмәгән.

Ясалган җир кишәрлеге түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- кирәк булганда һәм яңа инженерлык коммуникацияләрен салу өчен башка трассаны сайлау мөмкинлеге булмаганда, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, тоткарлыксыз керү мөмкинлеген;

- гамәлдәге инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, файдаланучы оешмаларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген.


Җир кишәрлегеннән алга таба файдаланганда:

- Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2018 елның 16 октябрендәге 31 номерлы әмере нигезендә Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Жуковский урамы, 4 адресы буенча урнашкан «Земство идарәсе бинасы» төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты (XIX гасыр ахыры, архитекторы билгесез) территориясеннән файдалану режимнарын;

- Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2017 елның 13 мартындагы 218од номерлы әмере белән расланган Казан шәһәренең төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне һәм сак предметын;

- Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2023 елның 1 декабрендәге 953-п номерлы әмере, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2010 елның 1 апрелендәге 183 номерлы «Истәлекле урын территориясен файдалануның характеры, әлеге территориядән файдалануга чикләүләр һәм хуҗалык эшчәнлегенә таләпләр, Казан шәһәренең истәлекле урыннары территориясендә проектлау һәм төзү турында нигезләмәне раслау хакында»гы әмере белән расланган «Казан шәһәренең XI-XVIII гасырлардагы тарихи үзәгенең мәдәни катламы» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектына карата чикләүләрне үтәү зарур.

# II. Территорияне ызанлау сызымы




| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| | ызанлау проектының чиге |
| | ясала торган җир кишәрлеге чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлегенең чиге |
| | кадастр кварталы чиге |
| :ЗУ1 | ясала торган җир кишәрлеге |
| | гамәлдән чыгарыла торган кызыл линияләр |
| | билгеләнә торган кызыл линияләр |
| н5 | ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы ноктасы |
| 3 | ызанлау проекты чикләренең характерлы ноктасы |
| к2 | билгеләнә торган кызыл линиянең характерлы ноктасы |

| | |
|---|---|
| ● 1 | инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы ноктасы |
| 16:50:010611 | кадастр кварталы |
| 16:50:010611:674 | җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| | беренчел җир кишәрлеге чиге |
| | инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чиге |